
# Мөслим районы Вәрәшбаш авылы мәчете ПОРТФОЛИОсы







**Авылыбызның имамы**
**Бәдретдинов Сәхипҗан**
**Газетдин улы**
**Авылыбызның абыстае**
**Низамиева Тәзкирә**
**Газетдин кызы**



# *Әз-мәз тарих......*

1817 нче елда Вәрәшбашта 184 йорт булып, аларга 2 мәчет, 3 кибет, 1 су тегермәне хезмәт күрсәткән.



1877 нче елда авылда 216 ир-ат, 224 хатын-кыз яшәгән, аларга 1 мәчет, 1 мәдрәсә хезмәт күрсәткән. 1895 нче елда бу мәчет (Оренбургтан кайткан архив материалларында ул соборный мәчет дип атала) кабат төзелә. Бу мәчет 421 ир-атны, 434 хатын-кызны берләштерә. Мәчет каршында мәдрәсә эшли. Метрика №1036.

Авылыбыздагы икенче мәчетне төзергә 1905 нче елның 2 нче мартында рөхсәт бирелә. Бу мәчет 1912 нче елның 13 нче сентябрендә төзелеп бетә һәм 3657 нче номер белән теркәп куела. Димәк, 2 нче мәчет 7 ел буе төзелгән. Мәчет төзү эшләрен Фәттәхетдинов дигән кеше кайгырткан. Кем икән ул кеше? Нәселе калдымы икән безнең авылда? Мондый фамилияле кешене авыл сакламаган, юк безнең авылда андый фамилияле кеше.  Эзләнәсе әйберләр күп әле безнең. Алары инде киләчәк буыннарга каладыр.

# Өр-яңа мәчет тарихы......

2010 нчы елда мәчет фундаментына таш салдынды. Авыл кешеләренең ярдәме бик тиде. Фундамент, идән-түшәмнәр өчен авыл халкы көче белән акча тупланды.

2012 нче елның 7 нче июнь көнне Розалия Габдрахманова үз акчасына мәчетне төзетә башлады. Авыл халкының аңа рәхмәте чиксез. Нәкъ 2 ай ярым дигәндә, 2012 нче елның 13 нче августында мәчеткә манара куелды, мәчет төзелеп бетте. Г. Розалиягә авыл кешеләренең чиксез рәхмәтләрен теркәп куям. Мәчет төзүдә зур өлешләрен керткән авылдашлар, райондашларның исемнәре: Хлюпин Руслан, Виктор; Низамов Фасил, Гумеров Илдар, Ахметханов Данис, Чариев Фидан, Зарипов.
19 нчы август көнне мәчеттә Ураза гаете укылды.





# Авылыбызга янәдән ИМАН нуры инде....





2006 нчы елның 17 нче мартында авылыбызга ямь өстәп, янәдән мәдрәсә эшли башлады. Мәдрәсәдә беренче (ничә еллардан соң беренче тапкыр) җомга намазы укылды. Бу көнне җомгага 12 ир-ат килде. 22 нче март көнне мәдрәсәне ачу тантанасы булды. Бик матур итеп бәйрәм табыны әзерләдек. Мөслимнең имам-мөхтәсибе Мөнир хәзрәт Борһанов (үзебезнең авыл егете, Ситдикъ абый белән Нажия апаның оныгы), Р. Габдрахманова, Р. Кирамов, Р. Ганиев, авыл җирлеге башлыгы Ф.Мәүлиева катнашты. Мөнир хәзрәт Борһанов белән бергәләп өйлә намазы укыдык.

2006 нчы елның октябреннән безнең авыл шәкертләрен махсус белемле Фәрит хәзрәт Нигъмәтҗанов укыта башлады. Гарәп хәрефләрен Тәзкрә Низамиева өйрәтте, ә дөрес уку кагыйдәләрен Фәрит өйрәтте, Гакыйдә фәненнән белемнәр бирде.

# Өлкәннәр өчен мәчет алды укулары: һәр атнаның дүшәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе






**“Нурлы китап” онлайн укулары оештырылды**

# Балалар өчен мәчет алды укулары:
# һәр атнаның сишәмбе көнендә









# Бакча, мәктәп балалары өчен мастер-класслар








# Җәмигъ мәчетендә абыстайлар җыены







## Вәрәшбаш авылы мәктәбендә “Буыннар элемтәсе” район семинары



# Безнекеләр өлгерә....

**Мөслим гимназиясенең 1Б сыныфында Сәхбетдинова Гөлсинә апа белән бик тәрбияви очрашу үтте. Әниләргә хөрмәт турында эчтәлекле класс сәгате булды.**

**https://www.instagram.com/p/B9YgOl6q4w1/?utm_source=ig_web_copy_link**




**“Күркәм киемле ханым” исемле кичәдә авылыбыздан 4 кызыбыз катнашты. Тулырак:**

**http://muslumirc.ru/news/stati/khebzr**



# Хуш киләсең, Рамазан!





- Авылыбыз имамы Сәхипҗан абый вәгазе
- Коръән уку бәйгесе
- Чыгыш: “Рамазан ае фазыйләте”, Низамиева Т.Г.
- Чыгыш: “Уразаны кемнәр тотарга тиеш?”, Сәхбетдинова Г.З.
- Дини иҗади күргәзмәгә йомгак ясау, Дипломнар тапшыру.
- Викторина “Ислам динен беләсеңме?”, Шәйдуллина Эльмира
- Авылда дини тәрбия бирүдә зур өлеш керткән кешеләргә Розалия хаҗия бүләкләрен тапшыру

# УРАЗА БӘЙРӘМЕ







# Мәүлид бәйрәме









# Бәраәт кичәсендә “Мәчет алды курслары”н уңышлы тәмамлаган шәкертләргә таныклыклыклар тапшырылды







# Мөслим буйлап сәяхәт.....






# “Урман иле” лагерыннан авылыбызга килгән кунаклар





Мөслимнең “Урман иле” лагерында мөселман балалары өчен ял оештырылды. Анда ял итүче 60 бала безнең Вәрәшбаш авылында экскурсиядә булдылар. Аларга экскурсоводларыбыз авылыбызның изге чишмә буйларын, мәчетне, авылыбызның “Туган як” музеен күрсәттеләр. Шулай ук авылыбызда үрнәк, тырыш Низамиева Тәзкирә апа, Җәләлов Әссәр абый, Баһауов Рәдифләрнең гаиләләрендә кунакта булдылар.

# Авыл мәктәбе оештырган бәйрәмнәрдә катнашу








# Дини лагерь

**Һәр ел саен Вәрәшбаш авылы мәчетендә Дини лагерь эшли. Анда 30-40 бала тәрбияләнә. Балалар көнгә 2 тапкыр кайнар аш белән тәэмин ителә, дини дәресләр ала, кызыклы һәм мавыктыргыч уеннар уйный. Лагерьны оештыруда Розалия хаҗия һәм авыл халкының ярдәме зур.**

**Тулырак мәгълүмат: http://chelny-rt.ru/news/sezd-nilr-bar/vrshbash-avyly-mchetend-islam-lagery-eshli**







# Мәчет терреториясендә, чишмә буйларында, зиаратта оештырылган өмәләрдә авыл халкы бердәм булып катнаша






# Иҗади конкурслар










**“Милость для миров” республикакүләмендә район мөхтәсибәте оештырган викторинада Сәхбетдинова Гөлсинә 1 урынны алды, Рәхмәт хаты белән бүләкләнде. “Туган авылым” Бөтенроссия иҗат конкурсында Низамиева Тәзкирә абыстай катнашып, җиңүче булды.**



# Үткәннәргә кайтып....


# “Нәсел шәҗәрәсе” төзү конкурсы



Низамиева Тәзкирә. Нәсел агачымның тамырлары, еракларга барып тоташа

ССЫЛКА на видео:

https://youtu.be/YHmFG-pvnqg




Миләүшә Хәсәнова. Фәрхетдиновларның нәсел шәҗәрәсе ССЫЛКА на видеозапись1:

https://yadi.sk/i/T89sXKs-Q0ia-Q

ССЫЛКА на видеозапись 2:

https://yadi.sk/d/lqVDTrrnqWgbcQ




**"Ак калфак" район иҗтимагый советы утырышларында безнең авылыбыздан даими катнашалар.**

**Тулырак: https://vk.com/wall-78072920?q="Ак%20калфак"%20&w=wall-78072920_29470**

**Конкурсның җиңүчеләре Ислам Хәсәнов һәм Асылъяр Хәсәновалар “Пәйгамбәрләр тарихы” китаплары белән бүләкләнделәр.**



## Дини тәрбия турында авылдашларыбызның иҗади язмалары, фикерләре

**Авылга нур иңдерүче** 4 август 2021

**Матур табигать, күңелне ертып керерлек көй, сокландыргыч биюләр. Болар барысы да кинода күргән искиткеч гүзәллек. “Кайда син юк, шунда рәхәт” дигән әйтем дә борынгылар авызыннан юкка гына чыкмагандыр. Үз күзләрең белән күреп, үз колакларың белән ишетеп, үз кулларың белән тотып, үз аякларың белән таптап карасаң гына, әйбернең ниндилеген тоясыңдыр ул. Заманында нинди матурлык дип сокланып караган Һиндстан җире дә, баксаң, искитмәле түгел икән, моны безгә авылыбыз имамы Сәхипҗан абый Бәдертдинов сөйләде.**

**Тулырак: http://muslumirc.ru/news/stati/avylga-nur-iderche**

**Ураза тәртипкә өйрәтә**

**– Ураза тотасыңмы? – Әйе, Аллага шөкер, Ходай җиңеллеген бирә. Аллаһы Тәгалә кабул итсен. – И, ураза тотуның нәрсәсе бар инде аның, бер өйрәнгәч... Әңгәмәдәшем фикерен әйтеп бетерергә дә өлгермәде, башыма: “Мин шулкадәр сабырсызмы?” – дигән уй килде. Ләкин әңгәмәдәшем, фикерен дәвам итеп:**
**– Үземнең тотканым юк, кеше әйткәнгә генә әйтүем, – дигәч, күңелгә бераз җиңел булып китте.**

**Тулырак: http://muslumirc.ru/news/stati/uraza-trtipk-yrtd**

# Дини тәрбия турында авылдашларыбызның иҗади язмалары, фикерләре

***Фитри иман белән тусак та...***

Һәр сабый дөньяга фитри иман белән туа, ягъни Аллаһка табынучы була. Нинди гаиләдә тәрбияләнүенә, нинди тәрбия алуына карап, ул үз динен сайлый. Кемдер христиан дине, кемдер буддизм дине канунары белән яши.

Тулырак: http://chelny-rt.ru/news/k%D3%99%D2%AFs%D3%99r-chishm%D3%99/fitri-iman-beln-tusak-ta

***Сорау….***Мәчеткә  килеп керү белән абыстай әбиләре кызларга яулык бәйләргә кушты. Шул мизгелдә Гөлинәнең башында тагын бер сорау туды, түзмәде: “Ә без нигә яулык   бәйлибез?”- диде ул. Абыстай әби шул кечкенә генә кызчыкныңсоравына шаккатып: “Ягез әле балалар, җайлап утырыйк та, дәресебезне Гөлинә биргән сорауга җавап табудан башлыйк,»- диде. – Безнең иңсәләребездә фәрештәләр утыра.

Тулырак: https://znanio.ru/media/ak_yaulyk_hikya-67419



***Әнкәй киңәше***

- Әни, әни, дим, кая син? – дип, ярсып кайтып керде Ислам мәктәптән. Юылган керләрен урнаштырып йөргән әнисе ашыга-ашыга улын каршыларга чыкты.
- Әни, дим, мин мәдрәсәгә бардым, кара әле маңгаемны тотып, гел шешеп бетте, - дип, кызу-кызу сөйләргә тотынды ул.
- Маңгаең белән егылдыңмени?
- Юк, әнием, намаз укыдым.

Тулырак: https://vk.com/doc358724834_449408577

## Дини тәрбия турында авылдашларыбызның фикерләре

**Авыл җирлеге башлыгы Земфира апа Маннапова белән әңгәмә: [https://vk.com/video358724834_456239356](https://vk.com/video358724834_456239356)**

**"Кешегә дини тәрбия бирү кайчан башланырга тиеш?" Мөхәммәдия мәдрәсәсе шәкерте Гөлсинә апа Сәхбетдинова фикере, тулырак: [https://vk.com/video358724834_456239357](https://vk.com/video358724834_456239357)**

**Мәктәп директоры Ләйсән Яхинаның фикере.Тулырак: : [https://vk.com/video358724834_456239354](https://vk.com/video358724834_456239354)**



**Авылыбыз абыстае Тәзкирә апа Низамиева белән әңгәмә: [https://vk.com/video358724834_456239355](https://vk.com/video358724834_456239355)**

# ВК соцчелтәрендә “Вәрәшбашым – Туган авылым” төркемендә дини темаларга мәгълүматлар туплау

https://vk.com/club194606972

Вәрәшбашым - туган ягым
13 янв в 13:14

Тәзкирә абыстай
Мөслим районы Вәрәшбаш авылында 1943 нче елда туган. Авыл мәктәбендә, аннан соң Мөслим урта мәктәбендә белем ала. Арча педагогия училищесы каршындагы курсларны тәмамлап, башлангыч класслар укытучысы булып эшли башлый.
Показать полностью...








Вәрәшбашым - туган ягым
30 июл в 12:44

Догалы йорт
29 июл 2021 в 19:00

Яхшы җеннәр безнең белән намаз да укый әле... (йорт иясе турында)


Яңа йортка күченгән бер танышым йорт иясен үзләре белән алып чыгулары турында сөйләгән иде. Бу динебезгә каршы килмиме? Йорт, мунча, абзар ияләре чынлап та бармы?

«Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы Нурулла хәзрәт Зиннәтуллин белән без сорауларга җавап эзләдек.
Показать полностью...



Вәрәшбашым - туган ягым
18 авг в 8:38

Догалы йорт
18 авг 2021 в 7:00




♥ ஐ´¯`МАТУР ДОГАЛАР...ИЗГЕ ТЕЛӘКЛӘР!´¯`ஐ ♥
صدق الله العظيم
Рәхмәт!
الله
ИҢ БЕРЕНЧЕ РӘХМӘТНЕ АЛЛАҺКА ӘЙТЕРГӘ ТИЕШБЕЗ...
АННАРЫ РӘХМӘТ ӘТКӘЙГӘ-ӘНКӘЙГӘ ..АЛАР БЕЗНЕ
ТУДЫРГАН..КЕШЕ ИТКӘН...ОЛЫ ЮЛГА ОЗАТКАН....
ЧИБӘР ДУСЛАРЫМ..РӘХМӘТ СЕЗГӘ..БИК ЗУР..
АЛЛАҺНЫҢ РӘХМӘТЕ ЯУСЫН..МИН СЕЗНЕ ЯРАТАМЫН..
ХӨРМӘТ ИТӘМЕН..ГӨЛСЕМ..

